# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О реализации Федерального закона «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2015 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

В целях реализации Федерального закона от 13 июля 2015 года № 220-ФЗ «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) настоящий Закон устанавливает полномочия органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления в сфере организации регулярных перевозок, порядок установления, изменения, отмены маршрутов регулярных перевозок, ведения реестров маршрутов регулярных перевозок и иные организационные основы осуществления регулярных перевозок по межмуниципальным и муниципальным маршрутам регулярных перевозок.

Статья 2. **Правовое регулирование отношений по организации регулярных перевозок**

Правовое регулирование отношений по организации регулярных перевозок осуществляется федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также нормативными правовыми актами органов местного самоуправления.

Статья 3. **Полномочия органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере организации регулярных перевозок**

1. Кабинет Министров Республики Татарстан в сфере организации регулярных перевозок:

1) принимает в пределах своей компетенции нормативные правовые акты Республики Татарстан, регулирующие организацию регулярных перевозок;

2) утверждает в пределах своей компетенции порядок подготовки документа планирования регулярных перевозок, принимает данный документ и организует его реализацию;

3) утверждает методику расчета и порядок возмещения из средств бюджета Республики Татарстан расходов перевозчиков, связанных с перевозкой пассажиров, пользующихся льготами на проезд;

4) осуществляет иные полномочия в соответствии с федеральным законодательством, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в сфере организации регулярных перевозок (далее – уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан):

1) разрабатывает проекты нормативных правовых актов Республики Татарстан, регулирующих организацию регулярных перевозок;

2) разрабатывает и реализует в пределах своей компетенции документ планирования регулярных перевозок;

3) выполняет функции государственного заказчика регулярных перевозок по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок, заключает государственный контракт, осуществляет контроль за исполнением условий государственного контракта и выдает карты маршрута регулярных перевозок;

4) выполняет функции организатора открытого конкурса на право осуществления перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок (далее – открытый конкурс), устанавливает шкалу для оценки критериев заявок на участие в открытом конкурсе, выдает перевозчикам свидетельство об осуществлении перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок, осуществляет контроль за их деятельностью;

5) устанавливает перечень остановочных пунктов, расположенных на территории Республики Татарстан, которые разрешается использовать в качестве начальных и (или) конечных остановочных пунктов по межрегиональным и межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок;

6) определяет и утверждает экологические характеристики транспортных средств, используемых для регулярных перевозок на территории Республики Татарстан;

7) утверждает порядок ведения реестров межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок, порядок установления, изменения, отмены межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок, ведет реестр

межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок, устанавливает, изменяет и отменяет межмуниципальные маршруты регулярных перевозок;

8) устанавливает порядок согласования мест посадки и высадки пассажиров на территориях поселений в Республике Татарстан при осуществлении межрегиональных перевозок пассажиров и багажа по заказу в случаях, предусмотренных Федеральным законом;

9) взаимодействует с федеральными органами исполнительной власти, органами местного самоуправления по вопросам организации регулярных перевозок и контроля за их осуществлением;

10) осуществляет иные полномочия, отнесенные к его компетенции федеральным законодательством, настоящим Законом, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия органов местного самоуправления в сфере организации регулярных перевозок**

Органы местного самоуправления в сфере организации регулярных перевозок:

1) принимают в пределах своей компетенции нормативные правовые акты, регулирующие организацию регулярных перевозок;

2) утверждают в пределах своей компетенции порядок подготовки документа планирования регулярных перевозок, принимают и реализуют его;

3) выполняют функции муниципального заказчика регулярных перевозок по муниципальным маршрутам регулярных перевозок, заключают муниципальный контракт, осуществляют контроль за исполнением условий муниципального контракта и выдают карты маршрута регулярных перевозок;

4) выполняют функции организатора открытого конкурса, устанавливают шкалу для оценки критериев заявок на участие в открытом конкурсе, выдают перевозчикам свидетельство об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок, осуществляют контроль за их деятельностью;

5) утверждают порядок ведения реестров муниципальных маршрутов регулярных перевозок, порядок установления, изменения, отмены муниципальных маршрутов регулярных перевозок, ведут реестр муниципальных маршрутов регулярных перевозок, устанавливают, изменяют и отменяют муниципальные маршруты регулярных перевозок;

6) устанавливают перечень остановочных пунктов, расположенных на территориях муниципальных образований, которые разрешается использовать в качестве начальных и (или) конечных остановочных пунктов по муниципальным маршрутам регулярных перевозок;

7) направляют в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан предложения по установлению остановочных пунктов на территориях муниципальных образований по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок;

8) взаимодействуют с федеральными органами исполнительной власти, органами исполнительной власти Республики Татарстан по вопросам организации регулярных перевозок и контроля за их осуществлением;

9) осуществляют иные полномочия, отнесенные к их компетенции федеральным законодательством, настоящим Законом, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 5. **Порядок установления, изменения, отмены муниципальных маршрутов регулярных перевозок, межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок**

1. Межмуниципальные маршруты регулярных перевозок в границах Республики Татарстан устанавливаются, изменяются, отменяются уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан.

2. Муниципальные маршруты регулярных перевозок в границах одного городского поселения устанавливаются, изменяются, отменяются уполномоченным органом местного самоуправления соответствующего поселения.

3. Муниципальные маршруты регулярных перевозок в границах двух и более поселений, входящих в состав одного муниципального района, устанавливаются, изменяются, отменяются уполномоченным органом местного самоуправления соответствующего муниципального района.

4. Порядок установления, изменения, отмены межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок, муниципальных маршрутов регулярных перевозок (в том числе основания для отказа в установлении либо изменении данных маршрутов, основания для отмены данных маршрутов) устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан, органами местного самоуправления соответственно.

5. Решения об установлении, изменении, отмене маршрутов регулярных перевозок размещаются на официальных сайтах уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченного органа местного самоуправления, принявших указанные решения, в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

6. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченный орган местного самоуправления, принявшие решение об отмене муниципального маршрута регулярных перевозок, межмуниципального маршрута регулярных перевозок, обязаны уведомить об указанном решении перевозчиков, осуществляющих регулярные перевозки по соответствующему маршруту, не позднее 180 дней до дня вступления указанного решения в силу в письменном или ином виде, позволяющем убедиться в получении адресатом уведомления.

7. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан, установивший маршруты межмуниципальных регулярных перевозок, осуществляет ведение реестра межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок.

8. Уполномоченный орган местного самоуправления, установивший в пределах своей компетенции маршруты муниципальных регулярных перевозок, осуществляет ведение реестра муниципальных маршрутов регулярных перевозок в соответствующем муниципальном образовании.

9. В реестры маршрутов регулярных перевозок должны быть включены сведения, установленные статьей 26 Федерального закона.

10. Сведения, включенные в реестры маршрутов регулярных перевозок, размещаются на официальных сайтах уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченного органа местного самоуправления, к полномочиям которых относится ведение данных реестров, в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Статья 6. **Организация регулярных перевозок**

1. В целях обеспечения доступности транспортных услуг для населения уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченные органы местного самоуправления в соответствии с Федеральным законом устанавливают муниципальные маршруты регулярных перевозок, межмуниципальные маршруты регулярных перевозок для осуществления регулярных перевозок по регулируемым тарифам и нерегулируемым тарифам.

2. Осуществление регулярных перевозок по регулируемым тарифам обеспечивается посредством заключения уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченным органом местного самоуправления государственных или муниципальных контрактов в порядке, установленном законодательством Российской Федерации о контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд, с учетом положений Федерального закона.

3. Регулируемые тарифы на перевозки по межмуниципальным, муниципальным маршрутам регулярных перевозок устанавливаются уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области регулирования тарифов.

4. Право осуществления регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок подтверждается свидетельством об осуществлении перевозок по соответствующему маршруту регулярных перевозок и картами соответствующего маршрута регулярных перевозок, выданными по результатам открытого конкурса, проводимого в порядке, установленном Федеральным законом.

Статья 7. **Выдача и прекращение действия свидетельства об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок и выдача карт соответствующего маршрута**

1. Свидетельство об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и карты соответствующего маршрута выдаются уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченными органами местного самоуправления, установившими данные маршруты.

2. Свидетельство об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и

карты соответствующего маршрута выдаются по результатам открытого конкурса в порядке, установленном Федеральным законом.

3. Без проведения открытого конкурса свидетельство об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и карты соответствующего маршрута выдаются в случае, если они предназначены для осуществления регулярных перевозок:

1) после наступления предусмотренных пунктами 1 и 2 части 1 статьи 29 Федерального закона обстоятельств и до начала осуществления регулярных перевозок в соответствии с новым свидетельством об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок, выданным по результатам проведения открытого конкурса;

2) по маршруту регулярных перевозок, установленному в целях обеспечения транспортного обслуживания населения в условиях чрезвычайной ситуации.

4. Без проведения открытого конкурса свидетельство об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок выдаются один раз на срок не более 180 дней в день наступления обстоятельств, которые явились основанием для их выдачи.

5. Действие свидетельства об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок прекращается при наличии хотя бы одного из обстоятельств, установленных частью 1 статьи 29 Федерального закона, в порядке, установленном частями 2–4 статьи 29 Федерального закона.

6. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченный орган местного самоуправления, выдавшие свидетельство об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок, обращаются в суд с заявлением о прекращении действия данного свидетельства при наступлении хотя бы одного из следующих обстоятельств:

1) неосуществление в отсутствие чрезвычайной ситуации предусмотренных данным свидетельством перевозок по маршруту регулярных перевозок в течение более чем трех дней подряд, а в случае осуществления перевозок по межрегиональным маршрутам регулярных перевозок, установленным уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, невыполнение более пяти рейсов подряд;

2) неоднократное в течение одного года привлечение юридического лица, индивидуального предпринимателя, хотя бы одного из участников договора простого товарищества, которым выдано данное свидетельство, к административной ответственности за совершение при осуществлении предусмотренных этим свидетельством перевозок административных правонарушений, указанных в частях 3–5 статьи 11.33 Кодекса Российской Федерации об административных правонарушениях;

3) расторжение договора простого товарищества (в случае, если данное свидетельство выдано участникам договора простого товарищества);

4) совершенное по вине водителя дорожно-транспортное происшествие, повлекшее причинение тяжкого вреда здоровью человека или смерть человека;

5) непредоставление перевозчиком ежеквартального отчета об осуществлении регулярных перевозок в порядке, установленном статьей 37 Федерального закона, более двух сроков подряд.

Статья 8. **Стоянка транспортного средства, используемого для осуществления регулярных перевозок, в ночное время**

1. Места расположения парковок в ночное время в границах Республики Татарстан определяются уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан по предложениям органов местного самоуправления.

2. Сведения о местах расположения парковок в ночное время размещаются на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Статья 9. **Обеспечение реализации положений настоящего Закона**

1. В рамках длящихся правоотношений с перевозчиками, у которых право осуществления регулярных перевозок возникло в соответствии с действующим до дня вступления в силу настоящего Закона порядком, организация регулярных перевозок осуществляется с учетом сроков, установленных статьей 39 Федерального закона.

2. Инвалидам (включая инвалидов, использующих кресла-коляски и собак-проводников) обеспечиваются условия для беспрепятственного пользования автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом, доступа к объектам транспортной инфраструктуры в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

Статья 10. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 13 ноября 2006 года № 70-ЗРТ «Об организации пассажирских перевозок, осуществляемых автомобильным и городским наземным электрическим транспортом общего пользования на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 11 (I часть); 2007, № 11; 2009, № 6; 2012, № 1, № 11 (I часть); 2014, № 12 (II часть);

2) Закон Республики Татарстан от 7 ноября 2007 года № 47-ЗРТ «О внесении изменения в статью 10 Закона Республики Татарстан «Об организации пассажирских перевозок, осуществляемых автомобильным и городским наземным электрическим транспортом общего пользования на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 11);

3) статью 2 Закона Республики Татарстан от 29 июня 2009 года № 24-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан в связи с образованием Комитета Республики Татарстан по тарифам» (Ведомости Государственного Совета Татарстан, 2009, № 6);

4) статью 2 Закона Республики Татарстан от 13 января 2012 года № 7-ЗРТ «О внесении изменения в статью 5.6 Кодекса Республики Татарстан об административных правонарушениях и признании утратившей силу части 6 статьи 11 Закона Республики Татарстан «Об организации пассажирских перевозок, осуществляемых

автомобильным и городским наземным электрическим транспортом общего пользования на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 1);

5) Закон Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 75-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об организации пассажирских перевозок, осуществляемых автомобильным и городским наземным электрическим транспортом общего пользования на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 11 (I часть);

6) Закон Республики Татарстан от 15 декабря 2014 года № 116-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об организации пассажирских перевозок, осуществляемых автомобильным и городским наземным электрическим транспортом общего пользования на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 12 (II часть).

Статья 11. **Порядок вступления в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Статьи 5–7 настоящего Закона вступают в силу с 11 января 2016 года.

3. Статья 8 настоящего Закона вступает в силу с 15 июля 2016 года.

4. Положение части 2 статьи 9 настоящего Закона применяется с 1 июля 2016 года исключительно ко вновь вводимым в эксплуатацию или прошедшим реконструкцию, модернизацию объектам.

5. Органам исполнительной власти Республики Татарстан в срок до 11 января 2016 года привести нормативные правовые акты Республики Татарстан в соответствие с положениями Федерального закона и настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БУЛЕК

Казань, Кремль
26 декабря 2015 года
№ 107-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – Федераль закон) гамәлгә ашыру максатларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара һәм муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларын алып бару һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның башка нигезләрен билгели.

2 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итә;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслый, бу документны кабул итә һәм аны гамәлгә ашыруны оештыра;

3) йөртүчеләрнең транспортта йөрүгә ташламалардан файдаланучы пассажирларны йөртүгә бәйле чыгымнарын исәпләү методикасын һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан каплау тәртибен раслый;

4) федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы):

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын эшли;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын эшли һәм аны гамәлгә ашыра;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның дәүләт заказчысы функцияләрен башкара, дәүләт контрактын төзи, дәүләт контракты шартларының үтәлешен тикшереп тора һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурсны (алга таба – ачык конкурс) оештыручы функцияләрен башкара, ачык конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора;

5) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлеген төзи;

6) Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларын билгели һәм раслый;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгели, үзгәртә һәм туктата;

8) Федераль законда каралган очракларда заказ буенча регионара пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территориясендә пассажирлар утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибен раслый;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп тору мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итә;

10) федераль законнар, әлеге Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә аның компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итәләр;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслыйлар, бу документны кабул итәләр һәм гамәлгә ашыралар;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль заказчысы функцияләрен башкаралар, муниципаль контракт төзиләр, муниципаль контракт шартларының үтәлешен тикшереп торалар һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

4) ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкаралар, ачык конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгелиләр, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр, аларның эшчәнлеген тикшереп торалар;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның

муниципаль маршрутлары реестрын алып баралар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгелиләр, үзгәртәләр һәм туктаталар;

6) муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктларының исемлеген төзиләр;

7) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

8) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны тикшереп тору мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек итәләр;

9) федераль законнар, әлеге Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенцияләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

5 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибе**

1. Татарстан Республикасы чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

2. Бер шәһәр җирлеге чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары тиешле җирлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

3. Бер муниципаль район составына керә торган ике һәм аннан күбрәк җирлекләр чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары тиешле муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибе (шул исәптән әлеге маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, әлеге маршрутларны туктату өчен нигезләр) тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

5. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату турында карарлар күрсәтелгән карарларны кабул иткән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле

җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

6. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын туктату турында карар кабул иткән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы йөртүчеләргә күрсәтелгән карар үз көченә керергә кимендә 180 көн кала язма рәвештә яисә адресатның хәбәр алуын расларга мөмкинлек бирә торган башка рәвештә әлеге карар турында хәбәр итәргә тиеш.

7. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара.

8. Үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле муниципаль берәмлектә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бара.

9. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына Федераль законның 26 статьясында билгеләнгән белешмәләр кертелгән булырга тиеш.

10. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр әлеге реестрларны алып бару вәкаләтләре бирелгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.

6 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру**

1. Халыкның транспорт хезмәте күрсәтүләрдән файдалана алуын тәэмин итү максатларында Федераль закон нигезендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, вәкаләтле җирле үзидарә органнары җайга салына торган тарифлар буенча һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгелиләр.

2. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия

Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт контрактлары яисә муниципаль контрактлар төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара, муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның җайга салына торган тарифлары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны җайга салу өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча җайга салынмый торган тарифлар белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрут карталары белән раслана.

7 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирү һәм аның гамәлдә булуын туктату, тиешле маршрут карталарын бирү**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары әлеге маршрутларны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс нәтиҗәләре буенча Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

3. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары, әгәр алар даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән булса, ачык конкурс үткәрмичә генә түбәндәге очракларда бирелә:

1) Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган шартлар барлыкка килгәннән алып даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне

һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә гамәлгә ашыра башлаганчы;

2) гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бер тапкыр 180 көннән артыграк булмаган срокка, аларны бирү өчен нигез булган шартлар барлыкка килгән көндә бирелә.

5. Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешендә каралган шартларның берсе генә барлыкка килгән очракта да даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы Федераль законның 29 статьясындагы 2 – 4 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә туктатыла.

6. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны биргән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы түбәндәге шартларның кимендә берсе барлыкка килгән очракта әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча әлеге таныклыкта каралган даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу гадәттән тыш хәлләр булмаган вакытта рәттән өч көннән артыграк вакыт дәвамында үтәлмәсә, ә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара маршрутлары буенча гамәлгә ашырылган очракта, рәттән кимендә биш рейс үтәлмәсә;

2) әлеге таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең кимендә бер катнашучысы әлеге таныклыкта каралган пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.33 статьясындагы 3 – 5 өлешләрендә каралган административ хокук бозуларны кылган өчен бер ел дәвамында берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылса;

3) гади ширкәт шартнамәсе өзелсә (әлеге таныклык гади ширкәт шартнамәсе катнашучыларына бирелгән очракта);

4) машина йөртүче гаебе белән кеше сәламәтлегенә авыр зыян салган яисә кеше үлеменә китергән юл-транспорт һәлакәте булса;

5) йөртүче Федераль законның 37 статьясында билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында квартал саен бирелергә тиешле хисапны рәттән ике тапкыр тапшырмаса.

8 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чарасын түнгә кую урыны**

1. Татарстан Республикасы чикләрендә түнге парковкаларның урыннары җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре буенча вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә.

2. Түнге парковкаларның урыннары турында белешмәләр вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

9 статья. **Әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган тәртип нигезендә барлыкка килгән йөртүчеләр белән дәвамлы хокук мөнәсәбәтләре кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру Федераль законның 39 статьясында билгеләнгән срокларны исәпкә алып башкарыла.

2. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларга (кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) автомобиль транспортыннан һәм шәһәр җир өсте электр транспортыннан тоткарлыксыз файдалана алу, транспорт инфраструктурасы объектларына керә алу өчен шартлар тәэмин ителә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 6; 2012, № 1, № 11 (I өлеш); 2014, № 12 (II өлеш);

2) "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2007 елның 7 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11);

3) "Тарифлар буенча Татарстан Республикасы комитеты төзелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2009 елның 29 июнендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6);

4) "Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.6 статьясына үзгәреш кертү һәм "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр

транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 6 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында" 2012 елның 13 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);

5) "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2012 елның 2 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш);

6) "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 15 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көчләренә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 5 – 7 статьялары 2016 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 8 статьясы 2016 елның 15 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге Законның 9 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләре 2016 елның 1 июленнән яңа гына кулланылышка тапшырылган яисә реконструкция, модернизация узган объектларга карата гына кулланыла.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары 2016 елның 11 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын Федераль закон һәм әлеге Закон нигезләмәләренә туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 107-ТРЗ